УДК 94(47).08

***Ч.Д. Миңнемуллина***

# КАЗАН ӘҖНӘБИ УКЫТУЧЫЛАР СЕМИНАРИЯСЕНДӘ МУЗЫКА УКЫТУ (XIX гасырның икенче яртысы)

В работе описан процесс становления музыкального образования в Казанской инородческой учительской семинарии. В статье рассматривается организация музыкальных занятий в этом учебном заведении, а также прослеживается роль Степана Васильевича Смоленского в развитии хорового пения на языках коренных народов Поволжья, оказавшего огромное влияние на становлении духовности воспитанников семинарии.

**Ключевые слова:** Казань, Казанская инородческая учительская семинария, музыкальные занятия, церковный хор, инородцы, С.В. Смоленский, Н.И. Ильминский.

Урта Идел буе халыкларына милли белем бирүнең формалашуында Александр II нең Бөек реформалар дәвере мөһим чор булып санала. Бу процесста Казан әҗнәби (җирле халык өчен ят телле) укытучылар семинариясе, Казан үзәк керәшен-татарлар мәктәбе аеруча зур роль уйный. Казан укытучылар семинариясен тикшеренүчеләр бу уку йортын бак хаклы рәвештә профессор, семинариянең беренче директоры Николай Иванович Ильминский системасын тормышка ашыруның уникаль үрнәге дип саныйлар [Исхаков, с. 105].

Казан укытучылар семинариясе авыл мәктәпләре һәм халык көллиятләре өчен укытучылар әзерләүче урта уку йорты булып санала. Анда, руслардан тыш, Россия империясенең көнчыгышта яшәүче күпсанлы милләтләр вәкилләре дә белем ала. Бу мәкаләдә сүз семинариядә тәрбияләнүчеләргә музыкаль сәнгать нигезләрен өйрәтүнең әлеге уку йорты бурычларын үтәүгә ничек ярдәм итүе хакында барачак.

Идел буендагы «рус булмаган» халыкларны православиегә тартуда музыкаль сәнгатьнең ролен чиркәү идеологлары һәм реформага кадәрге чор җәмәгатьчелегенең зыялылары яхшы аңлыйлар. Мәскәү университеты профессоры С.А. Рачинский, мәсәлән, болай дип яза: «Пение – единственная отрасль обучения, в которой успехи могут быть оценены непосредственно даже безграмотным родителем учащихся, возбуждает живой интерес в сельских жителях всех сословий» [Русская духовная…, т. 3, с. 357]. Россиядәге башка телле халыкларга музыкаль белем бирүнең әһәмияте дәүләт дәрәҗәсендә дә югары бәяләнә. Н.И. Ильминскийның Россия империясе халык мәгарифе министры Д.И. Деляновка язган отчетында мондый юллар бар: «Святейший синод считает чрезвычайно сильным орудием для привлечения язычествующих и магометанствующих инородцев к христианству употребление, согласно давним традициям пра-

вославной церкви, инородческих языков при церковном богослужении» [Ильминский, с. 12].

Музыкаль белем бирү, Казан укытучылар семинариясенә кадәр үк, Н.И. Ильминский тарафыннан оештырылган Казан үзәк керәшен-татар мәктәбендә актив алып барыла. Әйтик, XIX гасыр урталарында анда белем алучылардан чиркәү хоры оештырыла. Аны Алтай миссионеры, Мәскәүнең булачак митрополиты, Николай Ильминскийның якын дусты иеромонах Макарий башлап җибәрә. Ул Казанга Алтай миссиясе башлыгы, архимандрит Владимир тарафыннан керәшен-татар мәктәпләре оештырып, аларның эшен җайга салу максаты белән җибәрелгән була. Н.И. Ильминский гыйбадәт кылуны һәм чиркәү вәгазьләрен аз санлы халыклар телләрендә алып бара башлауга зур әһәмият бирә. Аның фикеренчә, бу ысул рус телен белмәүчеләрне чиркәү догаларының мәгънәсенә төшендерергә һәм аларны православие диненә тартырга ярдәм итәргә тиеш була [Колчерин, с. 126]. Һәм керәшен-татар мәктәбендә гыйбадәт кылу һәм догалар укуны әкренрәп татар телендә алып бара башлыйлар.

1871 елның августында керәшен татар мәктәбендә укучылар хорына Александр II каршында чыгыш ясау бәхете насыйп була. Император Казанда бөек кенәзләр белән Идел буйлап сәяхәт иткәндә тукталган була [Загоскин, с. 254–255]. Укучылар хоры император каршында татар, чуваш һәм чирмеш телләрендә «Коткар, Аллам»-ны («Спаси, Господи») башкара. Александр II аларның чыгышыннан бик канәгать кала. Изге Синодның 1880–1905 еллардагы обер-прокуроры К.П. Победоносцев та Казанга визиты вакытында бу уку йортында укучыларның музыкаль осталыгын югары бәяли. Н.И. Ильминский турындагы фикерләрен теркәгән хәтирәләрендә ул болай дип яза: «Все, имевшие случай посещать эту школу и слышать в церкви ее богослужение и пение на татарском языке, выносили оттуда истинную, восторженную радость русского сердца о том, чего могут достигнуть русские люди, связуемые любовью» [Победоносцев].

Н.И. Ильминский, Макарий Казаннан киткәннән соң да, татар телендә гыйбадәт кылуны дәвам итүдән туктау урынсыз дип саный. Керәшен-татар мәктәбе укучылары хорының яңа җитәкчесе вазифасын Василий Тимофеев үз кулына ала [Колчерин. с. 127].

Н.И. Ильминский, керәшен-татар мәктәбендә башка телләрдә алып барылган чиркәү җырларының уңышлы йогынтысын тоеп, Казанның әҗнәби укытучылар семинариясендә дә хор сәнгатен куллана башлауга зур игътибар бирә. Бу уку йортының, башлангыч мәктәп укытучыларыннан тыш, башка телдәге халыклар яши торган мәхәлләләр өчен руханилар (священниклар) әзерләвен дә истә тотып, семинаристларны укыту программасында чиркәү җырларына киңрәк урын бирелә башлый. Чиркәү идеологлары фикеренчә, «хор оештыру» һәр руханиның һәм чиркәү старостасының турыдан-туры бурычы булып исәпләнә, шуңа күрә семинарияне

тәмамлаган һәркем хор оештыру һәм аның белән җитәкчелек итү сәләтенә ия булырга тиеш санала [Русская доховная…, т. 3, с. 388].

Семинариядә музыканы беренче булып Степан Васильевич Смоленский укыта башлый. Ул, Казандагы Икенче ир балалар гимназиясен тәмамлаганнан соң, Казан Император университетының тарих-филология факультетына укырга керә. Студент елларында С. Смоленский музыкаль квартетларда катнашып, бик оста итеп скрипкада уйный. Нәкъ менә университетта укыганда ул хорда җырлау белән кызыксына башлый. Н.И. Ильминский белән С.В. Смоленскийны якын туганлык берләштерә. Н.И. Ильминский Казан әҗнәби укытучылар семинариясенә нигез салучы Степан Васильевичның туган апасына өйләнгән була. 1875 елда университетны тәмамлаганнан соң С.В. Смоленский, Н.И. Ильминский тәкъдиме белән, Казан әҗнәби укытучылар семинариясендә географиядән һәм җырдан укыта башлый. Семинариядә эшләвенең беренче елларда ул чиркәү җырларына өйрәтү алымнарын эшләү белән мәшгуль була. Аңа кадәр бу фәнне укытуның нигезле методикасы булмый әле. С.В. Смоленский укучыларның музыкаль белем дәрәҗәсен җырлау күнекмәләрен музыка теориясенә нигезләп тирәнәйтә бару аша күтәрергә омтыла. Мәсәлән, аның инициативасы белән семинаристларга сольфеджио дәресләре кертелә башлый [Русская духовная…, т. 3, с. 189].

1880 елларда инде аның эшчәнлеге нәтиҗәсе булып, җыр укытуның эшкәртелгән һәм шактый ныклы формалашкан методикасы барлыкка килә. Ул музыка дәресләрен өч төрле итеп уздыруга нигезләнә. Беренчесенә музыка теориясе, сольфеджио дәресләре керә. Әлеге алымнар семинарияне тәмамлаучыларга алга таба авылларда хорлар оештырырга ярдәм итәргә тиеш була [Ильминский, с. 19]. Икенче төре практик характерда була. Бергә җырлаганда хор чиркәү җырларын хәтеренә сеңдерә һәм аларны чиркәүдә җырлый. Мондый дәресләр атнага 3–4 тапкыр уздырыла. Өченче төр итеп, семинариядә белем алучыларның музыка коралларында (аерым алганда, скрипкада) уйнарга өйрәнүен санарга кирәк.

Рус һәм башка телләрне укыту программасы нигезендә чиркәү тарихлары, Иске һәм Яңа Гаһедләр турында сөйләгәндә музыкаль күнегүләрдән файдалана торган булалар. Шунысы кызык, андый музыкаль дәресләр программасы татарлар, чувашлар, чирмешләр һәм арлар өчен аерым төзелә. Күрәсең, монда ул телләрдәге укучыларның әзерлек дәрәҗәсе дә истә тотылгандыр. Н.И. Ильминский нәтиҗә ясаганча, керәшен татарлары дини яктан да, гомуми әзерлек, аеруча рус телен белүләре буенча да башкалардан өстенрәк булалар. Семинария директоры күзәтүләреннән мәгълүм булганча, аларның кайберләре кабул итү сынауларын рус мәктәпләрендәге яхшы укучылар белән бер дәрәҗәдә тапшыралар Н.И. Ильминский сүзләренә караганда, семинариягә килгән чувашлар күп яктан татарлардан түбәнрәк саналсалар да, арала-

рында рус телен шактый яхшы белгәннәре дә очрый. Чирмешләр белән арларны Н.И. Ильминский болай дип бәяли: «почти без исключения, весьма слабыми и в отношении общего развития, и в отношении знания русского языка» [Ильминский, с. 11]. Ә татар укучылар музыкаль күнегүләр буенча яхшы әзерлекле булулары белән аерылып торалар, чувашлар, арлар һәм чирмешләр исә Чиркәү җырлары, Литургияне һәм Пасха догаларын чиктән тыш уяулык, тырышлык белән генә ятлап башкара торган булганнар [Ильминский, с. 32].

С.В. Смоленский эшчәнлеге белән семинариядә Казанның күп кенә уку йортлары өчен үрнәк саналган хор оеша, шулай ук «Курс хорового пения» китабы да аның тырышлыгы нәтиҗәсе. Степан Васильевичта белем алган семинаристларны, бу уку йортын тәмамлаганнан соң, башка уку йортларына җыр укытучысы яки чиркәү хоры регентлары итеп чакыралар. С.В. Смоленскийның укучыларын хәтта Казан әҗнәби чиркәү хорының беренче җитәкчесе Макарий да югары бәяли. Бийскида епископ, шулай ук Алтай һәм Кыргыз миссияләре башлыгы Макарий 1891 елның 26 апрелендә С.В. Смоленскийга түбәндәге юлларны язып җибәрә: «Характер Вашего пения мне весьма нравится. Заключаю об этом по пению некоего Ташкинова, учившегося в Казанской учительской семинарии, состоявшего в Вашем хоре и теперь регентствующего в Улалинском хоре» [Воспоминания. Казань, Москва–Петербург, с. 531].

Казан әҗнәби укытучылар семинариясендә 15 ел эшләгәннән соң С.В. Смоленскийны Санкт-Петербургның Синод дәрәҗәсендәге җырлаучылар көллиятенә директор вазифасына билгеләләр. Әмма бу педагог китсә дә, аның белем бирү системасы таркалмый, XX гасыр башына кадәр аны укытучылар Н.И. Суворов белән Н.А. Александров тиешле югарылыгында дәвам итәләр.

## Әдәбият

*Загоскин Н.П.* Спутник по Казани. Иллюстрированный указатель достопримечательностей и справочная книжка города. Казань: DOMO «Глобус», 2005. 837 с.

*Ильминский Н.И.* Отчет Казанской учительской семинарии за 1889–90 и 1890–91 учебные годы. Казань, 1892. 36 с.

*Исхаков Р.Р.* Страницы истории Казанской учительской (инородческой) семинарии // Вестник Казанского государственного университета культуры и искусств. 2015. № 4–1. С. 105–108.

*Победоносцев К.П.* Из воспоминаний об Н.И. Ильминском // Русский вестник. Февраль 1892.

Русская духовная музыка в документах и материалах: в 8 т. М.: Языки славянской культуры, 2002.

*Колчерин С.А.* Православная миссия через просвещение: школы Н.И. Ильминского во второй половине XIX – начале XX вв. // Христианское чтение. 2013. № 1. С. 114–135.

***Миңнемуллина Чулпан Рамил кызы,***
*ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының*
*Өр-яңа тарих бүлеге аспиранты*
*e-mail: minchulpan@mail.ru*